СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 4-05-21; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamaduYsh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“13” июнь 2023 ел — №1-25

**«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелче үзгәрешләрне хупларга. (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 1-33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2003 елның 10 нчы июлендә Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының һәм башкарма комитетының административ бинасының утырыш залында: ТР, Мамадыш районы, Катмыш авылы, Ленин ур., 85 й адресы буенча уздырырга.

5. «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

кертү турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карары проекты буенча керүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Габдулбаров Р.Р. – 1 нче бермандатлы сайлау округы депутаты, төркем җитәкчесе;

2) Хазиев А.Р. – 2 нче бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Каримов Д.М.– 4 нчы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

6. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы каравына чыгарырга.

7. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының madysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы вазифаларын Р.Р.Габделбәровка йөкләргә.

Катмыш авыл җирлеге
Башлыгы вазифаларын башкаручы /Р.Р.Габделбәров/

СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН НИЖНЕСУНЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
1626001210

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Советының
13 июнь 2023 ел, №1-25 санлы
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр

19 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« Авыл торак пунктының Старостосы составына әлеге торак пункт кергән җирлек Советы тарафыннан авыл торак пунктындагы гражданнар җыены тәкъдиме буенча билгеләнә. Авыл торак пунктының Старостасы итеп әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары, йә тәкъдим ителгән көнгә 18 яшькә җиткән һәм шушы авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

2. 19 статьяның 3 өлешендә «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

319 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;
4. 31 статьяның 11 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5. 31 статьяның 12 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6. 31 статьяның 13 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

7. 41 статьяның 5 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;»;

8. 41 статьяның 1 өлешендә Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;»;

9 41 статьяга түбәндәге редакциядәге 1.1 өлеш өстәргә:
«1.1. Җирлек Советы депутаты нигезле сәбәпләр булмаганда алты ай дәвамында Җирлек Советының барлык утырышларында булмаган очракта, Җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

10. 44 статьяның 5 өлешендәге 12 пунктының б абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
11. 46 статьяның 8 өлешендәге 12 пунктындагы б абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
12. 47 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен « Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
13. 47 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктаткан, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданлыгы) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;»;

14. 80 статьяның 7 өлешендәге 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Советының
13 июнь 2023 ел, №1-25 санлы
карарына 2 нче кушымта

## «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

«Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет проектына гражданнар тәкъдимнәре Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422177, Татартсан Республикасы, Мамадыш районы, Катмыш авылы, Ленин урамы, 85 йорт, тел./факс: (885563) 4-05-21, e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru Ф.И.Аи., туган елын, тору урыны адресын түбәндәге таблица формасында күрсәтеп:

| № | Пункт, подпункт | проект карарының тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, Эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә әлеге карарны халыкка игълан иткән көннән 8 дән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар адрес буенча бирелә: на участие в публичных слушаниях с правом выступления подаются 422177, Татартсан Республикасы, Мамадыш районы, Катмыш авылы, Ленин урамы, 85 йорт, тел./факс: (885563) 4-05-21`, e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru ( (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлаулар» тамгасы белән), шулай ук тел./факс (885563) 4-05-21 буенча, e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru адресы буенча җибәрелә.

Гаризалар эш көннәрендә 8дән 16 сәгатькә кадәр ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеме тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Советка һәм«Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына тапшырыла.

Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм авыл жирлеге башлыгы вазыйфаларын бапшкаручыга тапшырыла.

Катмыш авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы /Р.Р. Габделбәров/

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НИЖНЕСУНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001210